ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

24 апрель, 2023 ел №145

«Җир салымы турында»гы карарга үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Апас шәһәр җирлеге Советы карар кылды:

1. «Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Апас шәһәр җирлеге советы 14.11.2014 21 номерлы карарына, 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«6. Салым түләүче оешмалар өчен хисап чорлары дип беренче квартал, икенче квартал һәм календарь елның өченче кварталы таныла.».

2. «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 8 ноябрендәге 118 номерлы Татарстан Республикасы Апас шәһәр җирлеге советы карарына, 3 пунктка «һәм аннан соңгы салым чорларын» сүзләренә өстәп, үзгәреш кертергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

«Апас шәһәр тибындагы поселок»
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Апас шәһәр җирлеге Советы рәисе А.Г. Җиһаншин